**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Сөйки авыл җирлеге Советының**

**КАРАРЫ**

**2019 елның 18 декабрендәге** **132 номерлы**

**“Кама Тамагы муниципаль районының Сөйки авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Сөйки авыл җирлеге Советы **КАРАР ИТТЕ**:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Сөйки авыл җирлеге Советының 2017 елның 15 июнендәге 49 номерлы карары белән расланган «Кама Тамагы муниципаль районы Сөйки авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. түбәндәге эчтәлекле 9.1 пункты кагыйдәләрен тулыландырырга:

«9.1. Наратлык балтырганының үрчүен туктату максатыннан, физик затлар ,үзләренең оештыру-хокукый рәвешләренә карамастан, үз милкендә булган җир кишәрлекләрендә наратлык балтырганын юк итү буенча чаралар үткәрергә тиеш.»;

1.2. 31 пунктын түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

«Тышкы суүткәргечле түбәләрне, калынлыгы 30 см. дан артык булган кар катламы барлыкка килүгә юл куймыйча, вакыт-вакыт кардан чистартырга кирәк.»;

түбәндәге эчтәлекле 35.14 пункты белән тулыландырырга:

«35.14. физик затлар һәм юридик затлар (шәхси эшмәкәрләр) тарафыннан үз милкендә яки файдалануда булган җир кишәрлекләрендә наратлык балтырганын юк итү буенча чаралар үткәрү.»;

1.3. түбәндәге эчтәлекле 105.1 пункты белән өстәргә:

«105.1. Автовокзалда, пристань, базарларда, паркларда, бакчаларда, ял итү зоналарында, мәгариф, сәламәтлек саклау, мәдәният учреждениеләрендә һәм халык күпләп йөри торган башка урыннарда, урамнарда, торак йортларның подъездларында, тукталышларда, сәүдә объектларына керү юлында кимендә ике чүп савыты куелырга тиеш. Чүп савытлары объектларның милекчеләре, арендаторлары тарафыннан урнаштырыла. Чүп савытлары тулган саен йорт милекчеләре һәм территорияләрне арендалаучылар тарафыннан чистартыла. Чүп савытларын буяу кирәк булган саен башкарыла. Чүп савытларын артык тутыру һәм пычрату тыела »;

1.4. түбәндәге эчтәлекле 115.2 пункты белән тулыландырырга:

«115.2. Юлның машиналар йөрү өлешендә механикалаштырылган җыештыру юл полотносында карның биеклеге 2,5-3,0 см га җиткәч башланырга тиеш, бу исә яңа яуган карның 5 сантиметрына туры килә. Механикалаштырылган җыештыру эшләре тәмамланганнан соң, юлның машиналар йөрү өлеше кардан һәм боздан тулысынча чистартылырга тиеш.

Урам һәм юллардан кар махсус әзерләнгән мәйданчыкларга чыгарылырга тиеш.».

2. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Сөйки авыл җирлеге Советының «Кама Тамагы муниципаль районы Сөйки авыл җирлеге муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында”гы.2017 елның 13 сентябрендәге 51номерлы карарының 1.32 пунктын гамәлдән чыгарырга.

3. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында игълан итәргә:

- ТР Кама Тамагы районы, Сөйки авылы, Кызыл Армия ур., авыл үзәге;

-ТР Кама Тамагы районы Сөйки авылы, Колхоз ур., 16а йорты , китапханә бинасы;

шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында һәм «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми игълан ителгән (басылып чыккан) көненнән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Татарстан Республикасы
Кама Тамагы муниципаль районы
Сөйки авыл җирлеге башлыгы,
Кама Тамагы муниципаль районы
Сөйки авыл җирлеге Советы рәисе: В. П. Никитин